**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап (ответы)**
**2020-2021 учебный год**
**10 класс**

Олимпиада состоит из 8 заданий. Внимательно ознакомьтесь с заданиями и выполните их. Рекомендуем выполнять задания последовательно, но принимаются и ответы, написанные в произвольном порядке.
Ответы можно вводить на компьютере в текстовом редакторе (только используйте татарские буквы) или писать от руки на бумаге. В случае написания ответов от руки необходимо прикрепить фото или скан-копию ответов.

**I. Һәр фразеологик гыйбарәне синоним булырдай бер фигыль белән алыштырып языгыз.** / Напишите каждый фразеологический оборот, заменив одним синонимичным глаголом. *(10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу)*
Йөзе качу, юлдан язу, кәкре каенга терәтү, кесә калынаю, күңелен кайтару, гайрәт чигү, борын салындыру, авызга су кабу, балавыз сыгу, күз эленү.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1) Йөзе качу – агарыну.
2) Юлдан язу – адашу.
3) Кәкре каенга терәтү – алдау.
4) Кесә калынаю – баю.
5) Күңелен кайтару – биздерү.
6) Гайрәт чигү – бизү.
7) Борын салындыру – боегу.
8) Авызга су кабу – дәшмәү.
9) Балавыз сыгу – елау.
10) Күз эленү – йокымсырау.

**II. Мисалларда тел уйнату нәрсәгә нигезләнгән? Ул кайсы термин белән атала? Әлеге алымны кулланып, *азык, каза, аяк, кабан* сүзләренең парларын языгыз. Шундый ук тагын 2 мисал китерегез /** На чём основана языковая игра в примерах? Каким термином она обозначается? Используя данный приём, запишите соответствующую пару для каждого слова: *азык, каза, аяк, кабан*. Приведите 2 аналогичных примера. (*10 баллов. 1 балл за объяснение сути приёма языковой игры; 1 балл за правильно указанный термин; по 1 баллу за каждое верно разгаданное слово; по 2 балла за каждый свой пример*.)

Тырма – тамыр, дус – суд, арка – кара

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1) Тел уйнату, сүз эчендәге хәрефләрнең урынын үзгәртеп, яңа сүз ясауга нигезләнгән.
2) Бу алым анаграмма дип атала.

3) Азык – казы
Каза – азак
Кыска – касык
Кабан – банка
4) Шат – таш
Бөтен – төбен

**III. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз. /** Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. (*15 баллов. 1,5 баллов за правильный разбор каждого слова.*)

Кеше үз гомеренең күпмедер өлешен нидер көтеп, нәрсәгәдер өметләнеп үткәрә.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Кеше – исем, уртаклык исем, тамыр исем, баш килештә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә ия.
Үз – алмашлык, билгеләү алмашлыгы, тамыр алмашлык, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, җөмләдә аергыч.
Гомеренең - исем, уртаклык исем, тамыр исем, иялек килешендә, берлек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән, җөмләдә аергыч.
Күпмедер – алмашлык, билгесезлек алмашлыгы.
Өлешен - исем, уртаклык исем, тамыр исем, төшем килешендә, берлек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән, җөмләдә тәмамлык.
Нидер – алмашлык, билгесезлек алмашлыгы.
Көтеп – хәл фигыль, беренче төр хәл фигыль, тамыр сүз, җөмләдә рәвеш хәле.
Нәрсәгәдер - алмашлык, билгесезлек алмашлыгы.
Өметләнеп хәл фигыль, беренче төр хәл фигыль, тамыр сүз, җөмләдә рәвеш хәле.
Үткәрә – фигыль, хикәя фигыль, хәзер заманда, 3 затта, берлек санда, җөмләдә хәбәр.

**IV. Лингвистик терминнар һәм тел берәмлекләре арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапны сан – хәреф формасында языгыз. /** Установите соответствие между лингвистическими терминами и языковыми единицами. Ответ представьте в виде: цифра - буква. *(10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу.)*

1) Паронимнар; 2) синонимнар; 3) тарихи сүзләр; 4) архаизмнар; 5) омонимнар; 6) диалектизмнар; 7) алынма сүзләр; 8) антонимнар; 9) Күп мәгънәле сүзләр; 10) Бер мәгънәле сүзләр.
А) Урам, терәү; Ә) Җиз, миләш; Б) Янчык – капчык; В) Измәче, үчегүчән Г) Ләкшә, үрә; Д) Әйләнә, иң; Е) Учма – тотам, үрнәк – өлге; Ж) Лашман, кассап; З) Игелек – изгелек, тибрәнү – тирбәнү; И) Тарханда, мисле.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1 – З
2 – Е

3 – Ж
4 – И
5 – Д
6 – Г
7 – Ә
8 – Б
9 – А
10 - В

**V. Рус телендәге гыйбарәләргә туры килә торган татарча вариантларын языгыз. /** Напишите татарские эквиваленты, соответствующие данным выражениям на русском языке. *(15 баллов. За каждый правильный вариант по 3 балла.)*
Вашими бы устами да мёд пить. Не было печали, так черти накачали. Видна птица по полёту. С больной головы на здоровую. По Сеньке и шапка.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Вашими бы устами да мёд пить - авызыгызга бал да май.
Не было печали, так черти накачали - авыртмаган башка тимер таяк.
Видна птица по полёту - ак карчыга очуыннан таныла, май чүлмәге тышыннан билгеле.
С больной головы на здоровую - ак эт бәласе кара эткә.
По Сеньке и шапка - чиләгенә күрә капкачы.

**VI. Сүзләрнең берсе тамырының мәгънәсе белән башкаларыннан аерылып тора. Әлеге сүзне һәм мәгънәсен языгыз. Шул тамырдан 2 яңа сүз уйлап языгыз. /** Одно из слов отличается от других значением корня. Запишите это слово и смысл. Из этого корня придумайте 2 новых слова. (*5 баллов. 3 балла за правильно указанное слово и смысл; по 1 баллу за каждое верно написанное слово*.)

Яралау, ярау, яраулы, ярашлы, яраклы

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Яралау – тәнне, эчке органнарны нәрсә белән булса да зарарлау, җөрәхәтләү.
Ярасыз, яралы

**VII. Татар телендә сүз ясалышы турынданиләр беләсез? Сүз ясалышының 1) өйрәнелеше; 2) ысуллары турында языгыз; 3) мисаллар китерегез. /** Что Вы знаете о словообразовании в татарском языке? Напишите об: 1) изучении; 2) способах; 3) приведите примеры. *(15 баллов. Каждый критерий оценивается 5 баллами.)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Сүзьясалыш татар тел белеменең мөстәкыйль бер тармагы булып тора. Шул ук вакытта ул аның башка бүлекләре – морфология, синтаксис, лексикология, фонетика, стилистика, семасиология һәм тел тарихы белән бәйләнгән.

**1) төрләре:** татар телендә синтетик, аналитик һәм кыскарма сүзләр билгеләргә мөмкин. Синтетик сүзләр Бу төр сүзләргә тамыр һәм кушымчалы сүзләр керә. Татар тел белемендә синтетик сүзләрне гади сүзләр дип йөртәләр. Тамыр сүзләр. Нигезләре тамыр белән тәңгәл килгән сүзләр тамыр сүзләр тәшкил итәләр, ягъни аларның составын нинди дә булса морфемаларга бүләргә мөмкин түгел: күз, кыш, ай, җир, ат, бар, үт. Кушымчалы сүзләр. Нигезгә кушымча ялганып ясалган сүзләр кушымчалы сүзләр булалар:
**2) Сүзьясалыш ысулы** – нинди дә булса телнең матди берәмлекләреннән, алар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре хасил итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы. Татар телендә сүзьясалышның түбәндәге ысуллары бар: 1) фонетик ысул; 2) кушымчалау ысулы; 3) сүзләр кушылу; 4) сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе; 5) сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе; 6) конверсия (лексик-грамматик ысул); 7) лексик-семантик ысул; 8) аббревиация (кыскартылмалар ясалышы).
**3) мисаллар китерегез.** Күз, кыш, ай, җир, ат, бар, үт. эш+лә (эш – нигез + фигыль ясаучы кушымча -лә); эш+че (эш – нигез + исем ясаучы кушымча -че), эш+чән (эш – нигез + сыйфат ясаучы кушымча -чән).

**VIII. Кайбер кешеләр компьютер уеннары чынбарлыктагы тормыштан кызыграк дип уйлый. Сез ничек уйлыйсыз? Сез бу фикер белән килешәсезме? Шуңа мөнәсәбәтегезне белдереп языгыз. Язмагыз 80 сүздән ким булмаска тиеш. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез. /** Некоторые люди считают, что компьютерные игры лучше чем жизнь. А вы как думаете? Вы согласны? Напишите сочинение (не менее 80 слов), выражая Ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера. *(20 баллов)*

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге.*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы.*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге.** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы.** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык.*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше.** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән. | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык. | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше.** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык. | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше.** | |
| | Грамматик хаталары юк. | 2 |
| | 1–2 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык. | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше.** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар. | 2 |
| | **2–3** хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык. | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше.** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк. | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк). | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше.** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл.** | | **20** |